ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 04.03.2026 329 **КАРАР**

«2026 - 2028 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында

Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 9 июлендәге 765 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026 - 2028 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «2017-2019 елларга Алабуга муниципаль районынның әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 24 гыйнварындагы 41 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2019 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 24 гыйнварындагы 41 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 13 сентябрендәге 1122 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2019 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 24 гыйнварындагы 41 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 17 гыйнварындагы 15 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2022 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 24 гыйнварындагы 41 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 декабрендәге 1690 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2024 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-

тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 24 гыйнварындагы 41 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 336 номерлы;

- «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2024 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында» 2017 елның 24 гыйнварындагы 41 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 19 декабрендәге 1683 номерлы.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) «2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районында әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен күздә тотарга.

4. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш һәм гамәлдә булу чоры 2026 елның 1 гыйнварыннан башлап барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4C332AC224D0671AE6BDE7AE77479904
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 02.02.2026 до 28.04.2027

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитеты
карарына кушымта

# «2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасы



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 3 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35

**«2026-2028 елларга**
**Алабуга муниципаль районының**
**әйләнә-тирә мохитне саклау»**
**муниципаль программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2026-2028 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2009 елның 15 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Экология Кодексы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Чулман (Кама) буе территориаль идарәсе (килешү буенча) |
| Программаны башкаручылар | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Чулман (Кама) буе территориаль идарәсе (килешү буенча) |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:<br>- районда экологик хәлне саклауга һәм тотрыклыландыруга юнәлтелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру;<br>- әйләнә-тирә табигать компонентлары буларак табигый ресурсларны саклау һәм яңадан җитештерү буенча чараларны гамәлгә ашыру;<br>- хуҗалык эшчәнлегендә экологик куркынычсызлыгын арттыру.<br><br>Программаның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертүне гамәлгә ашыру;<br>2. Район территориясендә табигый ландшафтларны яшелләндерү һәм саклау аша экологик-табигый каркас булдыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2026-2028 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетын формалаштыруны исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертергә (төгәлләштерелергә) тиеш. |



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 4 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

<table>
<tr><td></td><td>

| Финанслау чыганаклары | **2026** | **2027** | **2028** |
|---|---|---|---|
| Алабуга муниципаль район җирлеге бюджеты акчалары | 13 827,0 | 13 827,0 | 13 827,0 |
| Барлыгы | **13 827,0** | **13 827,0** | **13 827,0** |

</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм күрсәткеч нәтиҗәлелеге</td><td>Табигать ресурсларын (урманнарны, атмосфера һавасын, су, җир (туфрак), үсемлекләр ресурсларын, хайваннар дөньясы объектларын) саклау һәм рациональ файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, табигатьтән файдалану нәтиҗәсендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү, шул исәптән җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә дә, биологик төрлелекне саклау.</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру</td><td>Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.</td></tr>
</table>



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 5 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## I. Муниципаль программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы

Әлеге Программа «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2009 елның 15 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Экология Кодексы нигезендә эшләнгән.

Программа Алабуга муниципаль районында экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән чараларны үтәүгә бәйле муниципаль программаларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәҗрибәсен исәпкә алып эшләнгән.

Әлеге Программа Алабуга муниципаль районы территориясенең төп экологик проблемаларын хәл итүгә ярдәм итү дип танылды.

Программа әйләнә-тирәлекнең сыйфатын яхшырту нигезендә гражданнарның уңайлы яшәү шартларын булдыруга, хуҗалыкның аерым тармаклары һәм территорияләр белән идарә итү системасын камилләштерүгә, Алабуга муниципаль районында хуҗалык эшчәнлегенең экологик куркынычсызлыгын арттыруга юнәлдерелгән.

Программаның төп юнәлешләре булып: һава бассейнын, су ресурсларын саклау, җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү, табигый-экологик кадастрны үстерү һәм биологик төрлелекне саклау чаралары тора.

## II. Программаның максат һәм бурычлары

Программаның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- районда экологик хәлне саклауга һәм тотрыклыландыруга юнәлтелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру;
- әйләнә-тирә табигый мохит компонентлары буларак табигый ресурсларны саклау һәм яңадан җитештерү буенча чараларны гамәлгә ашыру;
- хуҗалык эшчәнлегендә экологик куркынычсызлыгын арттыру тора.

Программаның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү;
- район территориясендә ландшафтларны яшелләндерү һәм саклау аша экологик-табигый каркас булдыру.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026 – 2028 еллар.

Калдыкларны утильләштерү һәм эшкәртү, атмосфера һавасын саклау, су һәм җир ресурсларын саклау һәм рациональ файдалану, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын саклау буенча чаралар гамәлгә ашырылачак.

## III. Муниципаль программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны гамәлгә ашыру чыгымнарын Алабуга муниципаль районы бюджеты хисабына башкару планлаштырыла.



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 6 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетын формалаштыруны исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертергә (төгәлләштерелергә) тиеш.

Финанслауның гомуми күләме булачак:

мең сумнарда

| Финанслау чыганаклары | **2026** | **2027** | **2028** |
|---|---|---|---|
| Алабуга муниципаль район җирлеге бюджеты акчалары | 13 827,0 | 13 827,0 | 13 827,0 |
| Барлыгы | **13 827,0** | **13 827,0** | **13 827,0** |

## VI. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында заказчы төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген, чараларны гамәлгә ашыруның барышын һәм Программаны үтәүчеләрнең акчаларын нәтиҗәле куллануын тикшереп торуны тәэмин итә.

Программаны башкаручылар Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 25 числосына кадәр, ел саен хисап чорыннан соң килә торган айның 1 мартына кадәр, аның үтәлеше турында мәгълүмат тапшыралар.

## V. Муниципаль программаның икътисади социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген социаль, икътисади һәм экологик аспектларда карарга кирәк.

Икътисади нәтиҗә булып:

- су һәм һава пространствосына нормативтан тыш чыгарып ташлаулар, сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын утильләштерүнең заманча ысулларын гамәлгә кертү өчен түләүгә бәйле продукция җитештергәндә предприятиеләр чыгымнарын киметү;
- җитештерү һәм көнкүрешчүп-чарларның тискәре йогынтысын киметү тора.

Экологик нәтиҗә булып:

- әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметү һәм юк итү;
- әйләнә-тирә мохитнең торышы турында халыкның хәбәрдарлыгын арттыру;



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 7 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Социаль нәтиҗә булып:

- Алабуга муниципаль районы халкының сәламәтлеген яхшырту;
- әйләнә-тирә мохитнең торышы турында халыкның мәгълүматлылыгын арттыру;
- муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрендә халыкның кызыксыну дәрәҗәсен арттыру;
- гражданнарның әйләнә-тирә мохит торышы турында тотрыклы белемгә ия булуны оештыру ихтыяҗларын гамәлгә ашыру.



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 8 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**«2026-2028 елларга**
**Алабуга муниципаль районында әйләнә-тирә мохитне саклау»**
**муниципаль программасы чаралары**

| № т/б | Чаралар исеме | Башкаручы | Үткәрү вакыты | Суммасы, мең сум | Финанслау чыганагы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Алабуга муниципаль районында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2026 | 10687,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| 2. | Авыл җирлегендә елгалар суларын чистарту (килешү буенча) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2026 | 1540,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| 3. | Себер-түләмәле үләт базларының санитар-яклау зоналарын кыскарту | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2026 | 1600,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| | Барлыгы: | | | 13827,00 | | |
| 4. | Алабуга муниципаль районында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2027 | 1540,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| 5. | Авыл җирлегендә елгалар суларын чистарту (килешү буенча) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2027 | 10687,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| 6. | Себер-түләмәле үләт базларының санитар-яклау зоналарын кыскарту | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2027 | 1600,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын |



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 9 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | яхшырту |
| | Барлыгы: | | | 13827,00 | | |
| 7 | Алабуга муниципаль районында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2028 | 10687,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| 8 | Авыл җирлегендә елгалар суларын чистарту (килешү буенча) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2028 | 1540,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| 9 | Себер-түләмәле үләт базларының санитар-яклау зоналарын кыскарту | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2028 | 1600,00 | Муниципаль бюджет | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту |
| | Барлыгы: | | | 13827,00 | | |



Документ создан в электронной форме. № 329 от 04.03.2026. Исполнитель: Половинкина И.А.
Страница 10 из 11. Страница создана: 10.03.2026 16:35

Лист согласования к документу № 329 от 04.03.2026
Инициатор согласования: Половинкина И.А. Главный специалист
Согласование инициировано: 10.03.2026 16:36

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 10.03.2026 - 17:30 | - |